**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 30 ноябре № 5

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елн 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Иске Куак авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлар, көндезге бүлектә укучы студентлар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, мобилизацияләнгән гражданнар һәм МХО зонасында контракт буенча хезмәт итүче гражданнардан тыш, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) ремонт, киртәләр кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Иске Куак авылының православие зиратында иске агачларны һәм куакларны кисү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Куак авылындагы Мәктәп, Завод урамнары буенча юлга вак таш салу; Иске Куак авылындагы юлларны кардан чистарту);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Иске Куак авылы территориясендә үлән чабу).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин ур., 36 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Иске Куак авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сушкова